УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан ш.**

**«13» сентябрь, 2018 ел** **№ 66**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Граждан хәле актларын теркәү идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыруның кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Идарә башлыгы урынбасарына (Р.Х. Әхмәтҗанов) йөкләргә.

**Идарә башлыгы** **А.Р.Шәвәлиева**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2018 елның «16» сентябрендәге 66 номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Граждан хәле актларын теркәү идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Граждан хәле актларын теркәү идарәсендә (алга таба – Идарә) норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына, шулай ук Идарәдә эшләнә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына (алга таба – актлар, актларның проектлары) , Идарә актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алуны да кертеп, коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедурасы билгеләнә.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын тормышка ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә уздырыла.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып актларда һәм актларның проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү тора.

1.4. Коррупциягә каршы экспертизага килгән актлар (актларның проектлары) коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актларны һәм норматив

хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналында (алга таба – Журнал) (әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы) теркәлә.

1.5. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада бәяләмә төзелә, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага тапшырылган актның реквизитлары (акт проектының аталышы);

экспертиза уздыру нигезе;

актта (акт проектында) коррупциячел факторларның булуы яки юклыгы;

актның (акт проектының) коррупциячел факторларны үз эченә алган конкрет нигезләмәләре;

хокукый нормаларның тәгъбирләнешләрен үзгәртү яки коррупциячеллекне бетерү өчен аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр.

1.6. Актларга (актларның проектларына) коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен вәкаләтле зат башка норматив хокукый актлар белән бәйләнештә актка (акт проектына) бәяләмә уздыра.

## 2. Идарә актларына коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Идарә актларына коррупциягә каршы экспертиза Идарәнең хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге тарафыннан уздырыла. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы зат (алга таба – җаваплы зат) Идарә башлыгы боерыгы нигезендә билгеләнә.

2.2. Идарә актларына коррупциягә каршы экспертиза актларда аларның кулланылуына Идарәнең структур бүлекчәсе, җаваплы зат тарафыннан мониторинг уздырганда коррупциячел факторлар булуы ачыкланганда, шулай ук теләсә нинди ысул белән актларда коррупциячел факторлар булуы турында мәгълүмат алынганда уздырыла. Актлар шулай ук экспертиза уздыру өчен Идарә җитәкчелеге тарафыннан да җибәрелергә мөмкин.

Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

2.3. Актлар җаваплы зат тарафыннан тиешле мәгълүмат алынган яисә актны Идарә җитәкчелеге тарафыннан җибәргән көнне Журналда теркәлә.

2.4. Актка коррупциягә каршы экспертиза актны Журналда теркәгән көннән соң ункөнлек чорда уздырыла.

Актка коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре әлеге Тәртипнең 1.5 пункты нигезендә җаваплы зат тарафыннан төзелә торган бәяләмә белән рәсмиләштерелә һәм Журналда чагылдырыла.

Актка коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе турында бәяләмә төзелгән һәм имзаланган бер эш көненнән соңга калмыйча актны экспертизага юллаган затка хәбәр ителә.

2.5. Актта коррупциячел факторлар булуы турында бәяләмә җаваплы зат тарафыннан төзелгән һәм имзаланган бер эш көненнән соңга калмыйча Идарә башлыгына җибәрелә.

2.6. Идарә башлыгы актта коррупциячел факторлар булуы турында бәяләмә

нәтиҗәләре буенча аңа үзгәрешләр кертү зарурлыгы турында яки аның көчен югалтуын тану турында карар кабул итә.

2.7. Әлеге актны чыгару инициаторы булган структур бүлекчә Идарә башлыгы әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән башлап өч көнлек срокта Идарәнең тиешле акты проектын әзерли һәм аны коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы затка җибәрә. Мондый проектка коррупциягә каршы экспертиза әлеге Тәртипнең 3 бүлеге нигезендә уздырыла.

## 3. Идарә актлары проектларына, шулай ук Идарәдә эшләнә торган Татарстан Республикасы актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза

3.1. Идарә актлары проектларына, шулай ук Идарәдә эшләнә торган Татарстан Республикасы актлары проектларына (алга таба – актларның проектлары) коррупциягә каршы экспертиза Идарәнең җаваплы заты тарафыннан хокукый экспертиза уздырылганда үткәрелә.

3.2. Хокукый актлар коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Идарәнең структур бүлекчәсенең проектны эшләү өчен җаваплы булган вазыйфаи заты тарафыннан җибәрелә.

3.3. Килгән актларның проектлары җаваплы зат тарафыннан килгән көнендә Журналда теркәлә.

Коррупциягә каршы экспертиза проект теркәлгән көннән соңункөнлек чорда уздырыла.

3.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре әлеге Тәртипнең 1.5 пункты нигезендә җаваплы зат тарафыннан төзелә торган бәяләмә белән рәсмиләштерелә һәм Журналда чагылдырыла.

Коррупциячел факторлар булуы турында бәяләмә аны төзегән көнне Идарәнең проектны җибәргән структур бүлекчәсенә тапшырыла.

3.5. Коррупциячел факторлар булган очракта, Идарәнең проектны әзерләгән структур бүлекчәсе бәяләмәне алган көннән соң өч көнлек срокта проектны өстәмә эшләп бетерә һәм аны яңадан коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы затка җибәрә.

3.6. Кабат коррупциягә каршы экспертиза өстәмә эшләнгән проектны алган көннән соң өч көнлек срокта әлеге Тәртипнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында каралган тәртиптә уздырыла.

## 4. Идарә актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза

4.1. Идарәдә эшләнә торган һәм Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://zags.tatarstan.ru/rus рәсми сайтында (алга таба – сайт) һәм «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында аларга карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актларның проектларын урнаштыру өчен булдырылган, аларга

карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу өчен норматив хокукый актларның проектларын урнаштыру буенча бердәм төбәк интернет-порталы итеп билгеләнгән мәгълүмат ресурсында (алга таба – Мәгълүмат ресурсы) урнаштырылган, рәсми рәвештә бастырып чыгарылган норматив хокукый актлары һәм норматив хокукый актлары проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

4.2. Идарәнең актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Идарәнең акт проектын эшләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе акт проектын карау өчен Идарәнең хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенә (алга таба – бүлек) җибәрә. Идарә бүлеге башлыгы, акт карау өчен килгән көнгә туры килә торган эш көне дәвамында, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресын (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтеп, акт проектын сайтта урнаштыра.

4.3. Сайтта урнаштырылган актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты кимендә биш эш көне тәшкил итә.

4.4. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Идарәгә килгән бәяләмә (алга таба – бәяләмә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында теркәлә һәм Идарәнең актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә карау өчен җибәрелә.

4.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш итү холкына ия һәм алынган көненнән башлап Идарә тарафыннан 15 көнлек чорда зарури каралырга тиеш. Карау нәтиҗәләре буенча бәйсез экспертизаны уздырган юридик яки физик затка нигезләнгән җавап җибәрелә, бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш.

4.6. Акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар акт проектын өстәмә эшләү стадиясендә аны әзерләүче зат тарафыннан бетерелә.

4.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән кисәтүләрне юкка чыгаргач һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, акт проектын әзерләү буенча җаваплы булган структур бүлекчәсе акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәләрне теркәп, яңадан карап тикшерү өчен Идарә бүлегенә тапшыра. Кабат карау өч көнлек чорда гамәлгә ашырыла.

4.8. Әгәр актта коррупциячел факторлар ачыкланса, Идарәнең әлеге актны әзерләгән структур бүлекчәсе бәяләмә Идарәдә теркәлгән көннән башлап өч көнлек чорда актка үзгәрешләр кертү буенча яки аның көчен югалтуын тану турында чаралар күрә.

4.9. Идарә актларында һәм Идарә тарафыннан эшләнгән актларның проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән Идарә ризалашмаган очракта, Идарә, законнарда билгеләнгән тәртиптә, аталган актларны (актларның проектларын), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең

ризасызлыгын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

4.10. Проектны эшләүче зат Идарәдә эшләнгән Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында коррупциячел факторларның булуы турында таныклаучы коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракта, проектны эшләүче зат аталган норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә карау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

## 5. Идарәнең актлары проектлары турында иҗтимагый фикер алышу

5.1. Идарә эшләнә торган актларның проектлары турында иҗтимагый фикер алышуларны тәэмин итә.

5.2. Гражданнарның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына тия торган актларның проектлары иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен Мәгълүмат ресурсында урнаштырыла.

5.3. Иҗтимагый фикер алышу максатларында түбәндәгеләр урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләре яки конфиденциаль холыклы белешмәләре булган актларның проектлары;

актларны (аларның структур берәмлекләрен) көчен югалткан дип тану турында актларның проектлары;

аларны әзерләү өчен Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәсендә билгеләнгән срок иҗтимагый фикер алышуның минималь срогыннан азрак (Мәгълүмат ресурсында урнаштыру көненнән соң биш эш көненнән азрак) булган актларның проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яки чыгымнарына йогынты ясый торган актларның проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле актларның проектлары;

террорчылыкка, шул исәптән террорчылыкны финанслауга, каршы көрәш чараларын тормышка ашырганда дәүләт хакимияте органнарының эшчәнлеген оештыру, тәэмин итү һәм аларның үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен регламентлый торган актларның проектлары;

Татарстан Республикасы актларын законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән актларның проектлары;

суд карарларын, прокурор йогынтысы актларын, контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен тормышка ашыру максатларында әзерләнгән актларның проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында актларның проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында актларның проектлары.

5.4. Иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен актларның проектлары урнаштырылганда проект әзерләү инициаторы булган структур бүлекчә тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук иҗтимагый фикер алышу срогының башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

5.5. Әзерләүче тарафыннан актларның проектлары хакында иҗтимагый фикер алышу срогы Мәгълүмат ресурсында урнаштырган көненнән башлап биш эш көненнән азрак була алмый.

5.6. Проектны әзерләү инициаторы булган структур бүлекчә тарафыннан иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча акт проектын өстәмә эшләү турында карар кабул ителгән очракта, өстәмә эшләнгән акт проекты шулай ук иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштырыла.

5.7. Актларның проектларын Мәгълүмат ресурсында урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.8. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы, иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң 30 көнлек срокта документны эшләүче зат коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру барышында ачыкланган коррупциячел факторлар, иҗтимагый фикер алышу барышында килгән тәкъдимнәр турында җыелма мәгълүматларны аларны карау нәтиҗәләрен чагылдырып урнаштыра (әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ГХАТ идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларныж проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 1 нче кушымта

**Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналы**

| Актның (акт проекты-ның) экспертизага килү датасы | Актны (акт проектын) тапшырган структур бүлекчә | Актның (акт проекты-ның) аталышы | Коррупциячел норма-ларның булуы/ булмавы | Бәяләмәне төзү датасы | Искәрмәләр (кабат экспертиза уздырылуы турында мәгълүмат, кабат экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзү датасы) (актларның проектларына карата) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ГХАТ идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларныж проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 2 нче кушымта

**Коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәсе**

Идарәнең хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге тарафыннан «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2003 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, «Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе, «Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә, анда коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү өчен,

______________________________________________________________________________

(норматив хокукый актның реквизитлары яки норматив хокукый акт проектының аталышы)

________________________________________________________________актка коррупциягә каршы экспертиза уздырылды.

Коррупциячел нормаларның булуы яки булмавы:

______________________________________________________________________________

Акт проектының коррупциячел нормаларны үз эченә алган конкрет нигезләмәләре:

______________________________________________________________________________

Тәгъбирләнешләрне үзгәртү яки коррупциячеллекне бетерү өчен аерым нормаларны төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр:

______________________________________________________________________________

Җаваплы зат ________________________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ГХАТ идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларныж проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 3 нче кушымта

**Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм (яки) иҗтимагый фикер алышу йомгаклары буенча җыелма мәгълүмат**

___________________________________________________________________

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе норматив хокукый акты төре)

___________________________________________________________________

(норматив хокукый акт проектының аталышы)

**Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза**

| | Эксперт (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)/аккредитация турында күрсәтмә реквизитлары) | Ачыкланган коррупциячел фактор | Эшләүчедән аңлатмалар |
|---|---|---|---|

**Иҗтимагый фикер алышу**

| | Фикер алышуда катнашучы (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)/электрон почта адресы) | Фикер алышуда катнашучының позициясе | Эшләүчедән аңлатмалар |
|---|---|---|---|

Килгән тәкъдимнәрнең гомуми саны
Исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны
Өлешчә исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны
Исәпкә алынмаган тәкъдимнәрнең гомуми саны